РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2026 Кукмара ш. № 153

Муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген резервлау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 70.1 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауга бәйле кайбер мәсьәләләр турында» 2008 елның 22 июлендәге 561 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы «Нараткай» сәламәтләндер-ял итү учреждениесе (Лагерь)» МБУ территориясен киңәйтү максатларында, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Урта Комар авыл җирлеге адресында урнашкан 16:23:050102:296 кадастр номерлы җир кишәрлеген Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен резервларга.

2. Резервлау срогын әлеге карар кабул ителгән көннән алып 3 ел дип билгеләргә.

3. Объектларны милеккә яисә арендага тапшыруны, шулай ук физик яисә юридик затлар файдасына башкача читләштерүне тыюны билгеләргә.

4. Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына (Закиров И.Г.) җир кишәрлекләренә карата тиешле белешмәләрне Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертүгә бәйле тиешле гамәлләрне башкаруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**